**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительного комитета Азнакаевского муниципального района**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru


# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

**«14» июль 2020 ел** **№ 191**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының "Актүбә шәһәр тибындагы поселогының 1 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе" - "Әлкәй авылының төп гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең филиалын бетерү турында

Россия Федерациясе Граждан кодексының 61 - 63 статьяларына, 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 22, 102 статьяларына, 2003 елның 06 гыйнварындагы 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга таянып, Әлкәй авыл җирлеге гомуми җыелышының (гражданнар җыенының) 2020 елның 02 июлендәге беркетмәсен, Азнакай муниципаль районы муниципаль милке булган балалар өчен социаль инфраструктура объектын бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен алдан эксперт бәяләве уздыру буенча комиссиянең 2020 елның 03 июлендәге уңай бәяләмәсен исәпкә алып, **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогының 1 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең филиалы - «Әлкәй авылының төп гомуми белем бирү мәктәбе», урнашу урыны: 423309, Татарстан Республикасы, Азнакай шәһәре, Азнакай районы, Әлкәй авылы, Школьная урамы, 4 нче йорт (алга таба - филиал) ябарга.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының "Актүбә шәһәр тибындагы поселогының 1 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе" филиалы - "Әлкәй авылының төп гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең ликвидация комиссиясен, 1 нче кушымта нигезендә, төзергә.

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә ш.т. б. 1 нче урта мәктәбе уставына, 2 нче кушымта нигезендә, үзгәрешләр кертергә.

4. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә ш. т. б. 1 нче урта мәктәбе директоры (Г.К. Искәндәровага) гамәлдәге законнар белән билгеләнгән тәртиптә һәм срокларга туры китереп ликвидация буенча чараларның үтәлешен тәэмин итәргә:

- әлеге карар кабул ителгәннән соң өч көн эчендә филиалны бетерү турында юридик затны дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыручы органга законнарда билгеләнгән тәртиптә өч көн эчендә хәбәр итәргә;

- Россия Федерациясе Граждан кодексының 60 статьясындагы 1 пунктында билгеләнгән тәртиптә юридик затларны дәүләт теркәвенә алу турындагы мәгълүматлар бастырыла торган массакүләм мәгълүмат чараларында филиалны бетерү турында публикацияне бастырырга;

- "Актүбә шәһәр тибындагы поселогының 1 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» филиалы - «Әлкәй авылының төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе хезмәткәрләрен Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 180 статьясы таләпләренә туры китереп ликвидация турында шәхсән аңлатырга;

- филиалны бетерү турында ГКУ«Азнакай шәһәре халыкны эш белән тәэмин итү үзәге»нә хәбәр итәргә.

5. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет - телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

6. Әлеге карарныә үтәлешен контрольдә тотуны Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.Р. Гыйләҗевка йөкәргә.

Җитәкче А. Х. Шәмсетдинов

Азнакай муниципаль районы
Башкарма комитет
карарына 1 нче кушымта

«_____» _________ 2020 № ____

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының "Актүбә шәһәр тибындагы поселогының 1 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе" - "Әлкәй авылының төп гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең филиалын ликвидацияләү комиссиясе

*Комиссия рәисе:*

| | |
|---|---|
| Искәндәрова Гүзәл Касыймовна | Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Актүбә ш. т. б. 1 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе директоры |

*Комиссия секретаре:*

| | |
|---|---|
| Гәрәева Резедә Нуровна | "Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф идарәсе" МКУ әйдәп баручы белгече-юристы |

*Комиссия әгъзалары:*

| | |
|---|---|
| Фәрхетдинова Дилбәр Зәлфәровна | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе баш бухгалтеры |
| Садикова Луиза Миннесәгыйровна | “Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе " МКУ әйдәп баручы бухгалтеры |
| Раупова Алия Ягъфәровна | "Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе" начальнигы урынбасары |

«Расланган»
Азнакай муниципаль районы
Башкарма комитет карары

«___» __________2020 №______

_________________ А. Х. Шәмсетдинов

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ "АКТҮБӘ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ ПОСЕЛОГЫНЫҢ 1 НЧЕ УРТА УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘБЕ” УСТАВЫНА ҮЗГӘРЕШЛӘР МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЯСЕ УСТАВЫНЫ ҮЗГӘРЕШЛӘР**

Азнакай шәһәре

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2018 елның 23 апрелендәге 89 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Актүбә шәһәр тибындагы поселогының 1 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе уставы турында"  (2019 елның 09 сентябрендәге 272 номерлы карар редакциясендә) карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогының 1 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе уставына түбәндәге үзгәрешләр не кертергә:

1.5 пунктта:

җиденче-тугызынчы абзацларны төшереп калдырырга;

унынчы-уникенче абзацларны җиденче-тугызынчы абзац дип санарга.

1.6 пунктта:

бишенче-алтынчы абзацларны төшереп калдырырга;

җиденче-сигезенче абзацларны бишенче-алтынчы абзацлар дип санарга.